ГЛАВА КАНАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.4, д. Канаш, 422584

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КАНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 4 нче йорт, Канаш авылы, 422584

Тел.: (84379) 36-7-45, факс: (84379) 36-7-45.

12.04.2024 №3

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Түбән Күл  авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы бюджетыннан башка  Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына бюджетара трансфертлар бирү 22.11.2013 ел № 909 (29.11.2023 № 1532 редакциясендә) тәртибенең 2 пункты нигезендә “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең Түбән Күл авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” 2023 елның 19 октябрендәге 6 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы: - ремонт, коймалар төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Түбән Күл авылындагы зират территориясен төзекләндерү) дигән сорау буенча  2024 елның 12 апрелендә  узган гражданнар җыенының нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Гражданнар җыенының үткәрелгән этаплары нәтиҗәләре буенча йомгаклау беркетмәсенә  ярашлы, сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 123 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан җыенында катнашучылар саны 81 граждан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 81 кеше тавыш бирде,

«Юк» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең Түбән Күл авылында гражданнар җыенын булып узды, халык җыены нәтиҗәләре-дөрес дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең Түбән Күл авылына гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 19 октябрендәге 6 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә ризамы: - ремонт, коймалар төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Түбән Күл авылындагы зират территориясен төзекләндерү)» дигән мәсьәлә буенча карарны танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең Түбән Күл авылында узган гражданнар җыены нәтиҗәләрен Канаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Җыелышта рәислек итүче: Н.Н.Вальков